| СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

2018 елның 27 декабре №85

“Лениногорск муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Советының 2008 елның 15 октябрендәге 64 номерлы карары белән расланган “Лениногорск муниципаль районы" махсуслаштырылган муниципаль торак фондыннан торак биналар бирү тәртибе” турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы таләпләре нигезендә, "Россия Федерациясе Торак кодексының 103 нче статьясына үзгәреш кертү турында" 2017 елның 31 декабрендәге 488-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. “Лениногорск муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Советының 2008 елның 15 октябрендәге 64 номерлы карары белән расланган “Лениногорск муниципаль районы" махсуслаштырылган муниципаль торак фондыннан торак биналар бирү тәртибе” турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3.9 пунктта 4 подпунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4) инвалидлыгы эш бирүче гаебе белән эштә килеп чыккан I яки II төркем инвалидлар, хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә һөнәри авыру нәтиҗәсендә килеп чыккан I яки II группа инвалидлар, хәрби хезмәт бурычларын үтәгән вакытта алган яраланган, контузия яки гарипләнгән хәрби хезмәткәрләр арасыннан инвалидлар яисә хәрби хезмәт бурычларын үтәгәндә

яисә хәрби хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле авыру аркасында алган инвалидлары булган I яки II төркем инвалидлары, балалары инвалид булган гаиләләр, балачактан инвалидлар.

2. Әлеге карарны рәсми публикатор - «Лениногорские вести" газетында, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Лениногорск муниципаль районы башлыгы,

Совет рәисе Р.Г. Хөсәенов